Эшне башкару өчен кулланма

Татар теленнән белем һәм күнекмәләрне тикшерү өчен биремнәрне башкаруга 45 минут вакыт бирелә. Тәкъдим ителгән эш 2 өлештән тора.

Беренче өлеш 20 биремне үз эченә ала (А1-А20), сез алар арасыннан дөрес дип уйлаган җавапны сайлап алырга тиеш.

Икенче өлеш В1-В6 биремнәреннән тора. Әлеге биремнәр текстка бәйле рәвештә башкарыла. В1-В6 биремнәренә җавапны сез мөстәкыйль рәвештә формалаштырырга һәм язып куярга тиешсез.

Биремнәрне тәкъдим ителгән тәртиптә үтәгез. Аларны үтәү барышында сезнең өчен кыенлык тудырганнары килеп чыксса, әлеге биремне калдырып торып, алдагыларына күчәргә киңәш итәбез. Сез бу биремнәргә, вакытыгыз калган очракта, кабат әйләнеп кайта алачаксыз. Беренче өлештәге биремнәргә якынча 1,5 минут вакыт бирелә. Икенче өлештәге һәр биремгә 2 минут вакытыгызны сарыф итегез.

Дөрес җаваплар, катлаулылыкларыннан чыгып, 1 яки югарырак баллар белән бәяләнәләр. Әлеге балларны бергә кушканнан соң, сезгә гомуми балл чыгарыла, шуңа күрә мөмкин кадәр күбрәк биремнәргә дөрес җаваплар бирергә һәм күбрәк баллар җыярга тырышыгыз.

Сезгә уңышлар телибез !

4 вариант

1 өлеш (А)

Әлеге өлештәге биремнәрне (А1-А20) үтәгәндә, җавалар бланкында эшләнә торган бирем аста урнашкан, дөрес дип табылган җавап номеры шакмагына «Х» билгесе куегыз.

А1. Бер генә иҗектән торган сүзне табыгыз.

1. урак
2. май
3. китап
4. кояш

А2. Кайсы рәттәге сүзләрдә күпнокта урынына h хәрефе языла?

1....әтер, ...езмәт, ...ат, ...ыял
2. шә...әр, ...өнәр, ...ава, зин...ар
3. ...урлык, ...әбәр, бә...ет, ...әреф
4. ...олык, ...ата, ...айван, ...исап

А3. Сүзләрнең дөрес язылышы күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

1. кәгазь, сәгать
2. кагазь, сәгатъ
3. кәгәзь, сәгәть
4. кагәзь,сәгәть

А4. Ике хәреф, ике аваз гына булган сүзләр рәтен билгеләгез.

1. ямь, юл, аш, як
2. су, япь, яр, юк
3. эш,яз,уй,оя
4. аш, су, эл, ку

А5. **Э хәрефе язылган сүзне билгеләгез.**

1. б...лемле
2. бәйләд...
3. ...ремчек
4. җ...пшек

А6. Иҗекләргә дөрес бүленмәгән сүзләр рәтен билгеләгез.

1. чә-чәк-ләр, ка-ран-даш
2. ур-ман-чы-лык, са-бак-таш

3. зам-ан-да,мәз-әк
4. ур-наш-кан, үс-те-рә

А7. Сүзләрнең синонимик рәтен төзергә ярдәм итүче сүзлекне билгеләгез.

1. орфографик сүзлек
2. синонимнар сүзлеге
3. антонимнар сүзлеге
4. татарча-русча сүзлек

А8. Рәвешнең билгеләмәсен бигеләгез.

1. предметның эшен белдерә
2. эш яки хәлнең билгесен белдерә
3. предметны белдерә
4. предметның санын, исәбен белдерә

А9. Ялгызлык исемнәре булган рәтне билгеләгез.

1. әби, бабай,малай
2. авыл, кош,урман
3. Гариф, Мыраужан,Чулпан
4. ай, күпер,тылсым

А10. Кайсы төркемдә артык сүз бар?

1. кызылрак, зуррак, җылырак
2. япь-яшь, дөп-дөрес, көн-төн
3. көрәнсу, алсу, саргылт
4. айлы, түгәрәк, оста

А11. *Сезнең* **алмашлыгының килешен билгеләгез.**

1. иялек килеше
2. юнәлеш килеше
3. чыгыш килеше
4. урын-вакыт килеше

А12. *Ничә? Ничәү? Ничәнче? Ничәшәр?* **сорауларына кайсы сүз төркеме җавап бирә?**

1. Исем
2. Сыйфат
3. Фигыль
4. Сан

А13. Нечкә сузыклардан гына торган рәтне табыгыз.

1. авыл, капка, китап
2. каен, имән, юкә
3. әнкәй, бәби, тәпи
4. корт, күләгә, вышка

А14. Тамырдаш сүзләрне билгеләгез.

1. урак, урман, урды
2. көйлә, көйле, көйсез
3. сөлге, сөрт, сөртенде
4. карга, карлы, карсыз

А15. 3 зат, күплек сандагы хикәя фигыльләрдән генә торган рәтне билгеләгез.

1. укыйсын,барасың, язасың
2. укыйбыз, язабыз, уйныйбыз
3. укыйм, язам, уйныйм
4. укыйлар, язалар, уйныйлар

А16. Акыл эшчәнлеген белдерә торган фигыльләр рәтен билгеләгез.

1. төзи, башкара, сүтә
2. ерагая, үрмәли, бөтерелә
3. төшенә, килешә, чагыштыра
4. акыллы, зирәк, белемле

А17. Чыгыш килешендә булган сүзләр рәтен табыгыз.

1. кошларга,әнине,бүлмәнең
2. күнегүләрдә,хата,укучыга
3. капкадан,эттән,яшеннән
4. урманны,курчакка,бәйрәмне

А18. *о* **хәрефе языла торган сүзләр рәтен табыгыз.**

1. с...лге, ч...лмәк, п...ке
2. к....ры, п....чрак, ш....мырт

3. б...лыт, й...кы, т...рмыш
4. п..хтә, к..лке, с...рем

А19. Киләчәк заман хикәя фигыль булган сүзләр рәтен билгеләгез.

1. әйләнә, алып килә, сикерә
2. әйләнер, алып килер, сикерер
3. әйләнгән, алып килгән, сикергән
4. әйләнде, алып килде, сикерде

А20. Хата булган сүзләр рәтен күрсәтегез.

1. китабы, күлмәке, бакчасы
2. чүлмәге, тактасы, йөрәге
3. көрәге, сумкасы, алмасы
4. өе, тавыгы, ярмасы

2 өлеш (В)

Әлеге өлештәге биремнәрне, тәкъдим ителгән текст ярдәмендә үтәгәндә, җавапларыгызны җавап бланкында В1-В6 саннарының уң ягына беренче шакмактан башлап языгыз. Һәр хәреф яки цифр аерым шакмакка язылырга тиеш. Сүзләр яки цифрлар, санап үтелгәндә, аерым шакмакка куелган өтерләр белән аерыла. Җавапларны язганда буш шакмаклар калдырырга ярамый.

(1) Шул көннән башлап әти самавырны үзебезнең чишмә суыннан гына куйдыра торган булды.(2) Күршедә генә кое да бар югыйсә. (3) Суы да чип-чиста, тәмле, алып чыгу да җиңелрәк. (4) Чишмәдән китергәндә ике тапкыр тау менәсе бар.(5) Ә бу эш минем өстә.

В1. Икенче җөмләдәге калын әйтелешле сүзләрне языгыз**.**

В2. Текстан рус теленнән кергән алынма сүзне языгыз.

В3. Сыйфат булган җөмләнең санын күрсәтегез.

В4. Беренче җөмләнең иясен табыгыз һәм урын-вакыт килешенә куеп языгыз.

В5. Икенче җөмләнең әйтелү максаты буенча төрен билгеләгез.

В6. *Тәмле* сүзенең ясалышы ягыннан төрен билгеләгез.